**"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге «муниципаль берәмлегенең**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«20» ноябрь 2019 ел № 1

**Гажданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге составына керүче Яңа Оча авылында Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы нигезендә», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы», "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст.», Мамадыш муниципаль районы Яңа Оча авылында 2019 елның 20 нояберендә узган үзара салым акчаларын куллану һәм кертү буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

" Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Яңа Оча авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннар, көндезге бүлектә белем алучы студентлар кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Яңа Оча авылы торак пункты урамнарын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Яңа Оча авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

« ӘЙЕ» «ЮК»

соравы буенча 2019 нчы елның 20 нче ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 73 граждан кертелгән; гражданнар җыенында катнашучы 49 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Халык җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе " позициясе өчен»- барлыгы 49 кеше тавыш бирде;
“Юк” дип тавыш бирүче булмады.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Яңа Оча авылында үткән гражданнар жыенын- уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Яңа Оча авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:

" Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Яңа Оча авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннар, көндезге бүлектә белем алучы студентлар кала, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Яңа Оча авылы торак пункты урамнарын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Яңа Оча авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Җ.Хәмизуллин